| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 май № 323

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 29 май, 340 нчы; 2009 ел, 2 февраль, 56 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1156 нчы; 2011 ел, 4 ноябрь, 918 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 696 нчы; 2013 ел, 16 декабрь, 995 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 52 нче; 2015 ел, 26 февраль, 116 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 2.1.7 пункт өстәргә:

«2.1.7. Финанс-бюджет тармагында эчке дәүләт финанс контролен һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасының баш администраторлары тарафыннан эчке финас контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыруны анализлауны башкару.»;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Министрлык әлеге Нигезләмәнең 3.1 һәм 3.2 пунктлары нигезендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

Татарстан Республикасы бюджет системасын һәм бюджетара мөнәсәбәтләрне камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм чараларны тормышка ашыра;

билгеләнгән тәртиптә озак вакытлы, урта вакытлы һәм кыска вакытлы перспективаларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразларын эшләүдә катнаша;

озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразы проектын (бюджет фаразы үзгәрү проектын) эшли;

икътисадны финанс сәламәтләндерү һәм структуралы үзгәртеп кору буенча, үз илебезнең товар җитештерүчеләре, эшләр башкаручылары һәм хезмәт күрсәтүчеләре мәнфәгатьләренә булышлык күрсәтү һәм аларны яклау буенча чаралар эшләүдә һәм аларны гамәлгә ашыруда катнаша;

эре салым түләүчеләр түләүләренә мониторинг үткәрә;

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын әзерләүдә катнаша, билгеләнгән тәртиптә аларны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауны тәэмин итә;

Татарстан Республикасында инвестиция сәясәтен тормышка ашыруга юнәлгән чаралар эшли, республиканың инвестицион программаларын эшләүдә һәм финанслауда катнаша;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы закон проектларын һәм бүтән норматив хокукый актларын эшләүдә катнаша;

үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә норматив хокук актлары эшли һәм кабул итә;

дәүләт акчасын нәтиҗәле файдалану турында тәкъдимнәр эшләү буенча икътисадый профильдәге фәнни-тикшеренү оешмалары белән үзара бәйләнештә була;

үзенең территориаль органнарын мәгълүматлаштыру өлкәсендә бердәм сәясәт үткәрүне тәэмин итә;

Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзи һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә;

Татарстан Республикасының консолидацияләнгән бюджеты фаразын эшли;

үз компетенциясе кысаларында Татарстан Республикасы бюджетын башкара, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасының консолидацияләнгән бюджеты үтәлеше турында хисаплар төзи;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында хисап кертә;

Татарстан Республикасы бюджетының җыелма исемлеген төзи һәм алып бара;

Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзү һәм Татарстан Республикасы бюджетын үтәү өлкәсендә методик җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы бюджеты, шулай ук законнарда каралган очракларда җирле бюджетлар үтәлешен беренчел һәм алга таба тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра;

финанс-бюджет өлкәсендә эчке дәүләт финанс контролен гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының баш администраторлары тарафыннан эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыруга анализ үткәрә;

дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында законнарны үтәүне тикшерүдә тоту буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру кысаларында шикаятьләр, планлаштырылган һәм планнан тыш тикшерүләр, алар буенча кабул ителгән карарлар һәм бирелгән күрсәтмәләр реестрын алып баруны гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы дәүләт чыгымнары структурасын камилләштерүгә юнәлгән тәкъдимнәр әзерли һәм чаралар күрә;

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасын һәм аларның структурасын камилләштерү турында тәкъдимнәр эшләүдә катнаша; Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары аппаратлары, аларның территориаль органнары хезмәткәрләренең чик саны һәм әлеге органнар аппаратларын карап тотуга ассигнованияләр күләме турында тәкъдимнәр әзерли; бюджет учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү системасын камилләштерү турында тәкъдимнәр әзерләүдә катнаша;

бюджетны планлаштыру өлкәсендә бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлгән методологик җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

салым сәясәтен камилләштерү, салым турында законнарны үстерү хакында тәкъдимнәр эшләүдә катнаша;

төбәк салымнары һәм җыемнары турында Татарстан Республикасы законнарын куллану мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;

оператив идарә итү хокукында Министрлыкка беркетелгән дәүләт мөлкәте белән билгеләнгән тәртиптә идарә итүне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы дәүләт бурычы белән идарә итү мәсьәләләре буенча, шул исәптән аның структурасын камилләштерү һәм аңа хезмәт күрсәтүгә чыгымнарны оптимальләштерү буенча тәкъдимнәр кертә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасының дәүләт эчке алынмалары программасын, Татарстан Республикасы дәүләт заемнарын чыгару һәм урнаштыру шартларын эшли;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасының дәүләт тышкы алынмалары программасын эшли;

бюджет турында законнарда каралган очракларда Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасының дәүләт эчке алынмаларын гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен бирү тәртибе программасын эшли;

Татарстан Республикасының Дәүләт бурычы китабын алып бара;

муниципаль берәмлекләрнең муниципаль бурыч китапларын алып баручы органнарга тапшырыла торган муниципаль берәмлекләрнең тиешле муниципаль бурыч китапларында чагалыш тапкан бурыч йөкләмәләре турында мәгълүматны хисапка ала;

Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләре реестрын алып бара;

Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешенең касса планын төзүне һәм алып баруны гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы бюджетының табыш чыганаклары реестрын формалаштыра һәм алып бара;

Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән расланган акча лимиты кысаларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә бюджет кредитлары бирүне үтәүне тәэмин итә;

Татарстан Республикасы бюджет акчасы белән баш идарә итүчеләр, идарә итүчеләр һәм алучыларның җыелма реестрын алып бара һәм эшчәнлекләре Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган бюджет учреждениеләрен теркәүне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәсе буенча халыкара финанс оешмалары белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра, финанс сәясәте һәм кредит килешүләре төзү мәсьәләләре буенча алар белән билгеләнгән тәртиптә сөйләшүләр һәм консультацияләр үткәрә;

финанс, кредит һәм валюта мөнәсәбәтләре өлкәсендә хөкүмәтара һәм дәүләтара шартнамәләр проектларын әзерләүдә катнаша;

Татарстан Республикасында бухгалтер исәбе һәм хисаплыгы белән методологик идарә итү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм чаралар күрә;

бюджет акчасын алучыларның, шулай ук бюджет кредитларын алучыларның финанс хәлен тикшерүләр үткәрә;

үзе билгеләгән тәртиптә бюджет кредитларын тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантияләренең, җаваплылыкны үз өстенә алуның ышанычлылыгын (ликвидлылыгын) бәяләүне гамәлгә ашыра;

гарантия буенча йөкләмәләрне тулы күләмдә яки кайсы бер өлешендә үтәгән гарантның принципалга регресслы таләпләрен белдерүе белән бәйле киләчәктә барлыкка килергә мөмкин булган принципалның финанс хәленә һәм бирелгән принципал бурычларын үтәүне тәэмин итүнең ликвидлылыгына (ышанычлылыгына) тикшерүләр үткәрә;

Татарстан Республикасында кыйммәтле кәгазьләр базарын үстерү турында тәкъдимнәр эшләүдә катнаша;

бюджет инвестицияләрен алу шартларын саклауга һәм файдалануның нәтиҗәлегенә тикшерүләр үткәрә;

Татарстан Республикасы территориясенә чит ил инвестицияләрен җәлеп итү, аларны урнаштыруның дәүләт сәясәтен эшләүдә катнаша;

Министрлыкны карап тотуга һәм һәм Министрлыкка йөкләнгән функцияләрне тормышка ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының баш идарә итүчесе һәм алучысы функцияләрен башкара;

Министрлык хезмәткәрләренең һөнәри яңадан әзерлеген һәм квалификацияләрен күтәрүне оештыра;

Татарстан Республикасы закон актларында каралган очракларда тапшырылган дәүләт вәкаләтләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылуын, шулай ук дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына бирелгән финанс чараларын максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны башкара;

Татарстан Республикасы закон актларында каралган очракларда җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда билгеле булган бозуларны бетерү турында язмача күрсәтмәләр җибәрә, шулай ук билгеле булган бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү өчен кирәкле бүтән чаралар күрә;

Татарстан Республикасы закон актлары белән карлаган очракларда һәм тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату турында тәкъдимнәр һәм тиешле Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына кертә;

Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм җирле үзидарә органнары арасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә һәм шартларда бюджет

акчасын файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү һәм җирле бюджетларның салым һәм салым булмаган керемнәрен арттыру буенча чаралар турында килешүләр әзерләүне һәм төзүне тәэмин итә;

дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында законнар белән билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында Татарстан Республикасы ихтыяҗларын һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы функцияләрен башкара;

Министрлыкның мобилизацион әзерлеген һәм мобилизациясен оештыра һәм тәэмин итә, ведомствосындагы оешмаларның мобилизацион әзерлек буенча чаралар үткәрүен яраштыра, тикшерүдә тота һәм тәэмин итә, шулай ук әлеге чараларны методик тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

бюджет йөкләмәләре лимитлары, финанслау чыганаклары, кредит бурычлары, сатып алуларның нәтиҗәлелеген раслау булу өлешендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары, муниципаль ихтыяҗлар (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен заказлар урнаштыруны килештерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга сала торган килешү булганда), Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре ихтыяҗлары, муниципаль бюджет учреждениеләре ихтыяҗлары (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан муниципаль бюджет учреждениеләре ихтыяҗлары өчен заказлар урнаштыруны килештерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга сала торган килешү булганда) өчен заказлар урнаштыруны килештерү буенча вәкаләтле орган була;

эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминиятләвенә иминият кертемнәрен түләүче Татарстан Республикасында эшләмәүче гражданнарны иминиятләүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру методикасы нигезендә үз компетенциясе кысаларында Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыра;

гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү өчен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә, үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча телдән һәм язма формаларда хокукый консультация күрсәтү рәвешендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтә;

федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары белән билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә социаль ярдәмгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга гаризалар, шикаятьләр, соратулар һәм хокукый характердагы башка документлар төзү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә һәм судларда, дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда граждан мәнфәгатьләрен яклый;

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль түләүләре турында мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасын алып бара;

законнар нигезендә бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.».

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының заказлар урнаштыруны килештерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруы турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1156 нчы карарының 4 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2012 ел, 08 октябрь,839 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2013 ел, 31 гыйнвар, 63 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 19 март, 189 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль түләүләре турында мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2013 ел, 16 декабрь, 995 нче карарының 7 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын үз көчен югалаткан дип тану хакында» 2014 ел, 18 март, 169 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2014 ел, 10 июнь, 395 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков